**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл жирлеге БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 ноябрь, 2021 ел №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, **карар итәм**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылындагы КФҮ бинасында 2021 елның 7 декабрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылындагы КФҮ бинасында 2021 елның 7 декабрендә 11.30 сәгатькә билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылындагы КФҮ бинасында 2021 елның 7 декабрендә 13.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2021 елда Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум  күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;

2) территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

3) кышкы чорда юлларны чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү;

4) бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декадасы», «Яңа ел»).;

5) МТЗ-82 өчен отвал сатып алу,

6) чаралар үткәрү өчен аппаратура һәм җиһазлар сатып алу?

« РИЗА»                                                            «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Сарлы авылы, Үзәк урамы, 68А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык                                                                                     М.Р.Шарипов